Татарстан Республикасы
Балык Бистәсе муниципаль районы
Балык Бистәсе шәһәр җирлеге Советы

**КАРАР № 13-1**

Балык Бистәсе штп. 2018 елның 24 сентябре

Гражданнарның үзара салым акчаларын кертү һәм файдалану мәсьәләсе буенча Балык Бистәсе шәһәр җирлеге территориясендә җирле референдум билгеләү турында

2002 елның 12 июнендәге "Россия Федерациясе гражданнарының сайлау хокуклары һәм референдумда катнашу хокукының төп гарантияләре турында" 67-ФЗ номерлы Федераль законның 15 маддәсенә, 2003 елның 6 октябрендәге "Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында" 131-ФЗ номерлы Федераль законның 22, 56 маддәләренә, 2004 елның 28 июлендәге "Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында" 45-ЗРТ номерлы Татарстан Республикасы законының 20 маддәсенең 1 өлеше 1 пунктына, 2004 елның 24 мартындагы "Җирле референдум турында" 23-ЗРТ номерлы Татарстан Республикасы законының 12 маддәсенең 1 пункты "в" пунктчасына, 18 маддәсенә, Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы "Балык Бистәсе шәһәр тибындагы поселогы" муниципаль берәмлеге Уставының 11 маддәсенә ярашлы рәвештә, Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Балык Бистәсе шәһәр җирлеге Башкарма комитетының 2018 елның 21 сентябрендәге "Референдум үткәрү инициативасы турында" 12-1 номерлы карары, Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Балык Бистәсе шәһәр җирлеге Советының 2018 елның 21 сентябрендәге "Референдум үткәрү инициативасы турында" 12-1 номерлы карары нигезендә Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Балык Бистәсе шәһәр җирлеге Советы КАРАР БИРӘ:

1. Гражданнарның үзара салым кертү мәсьәләсе буенча Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Балык Бистәсе шәһәр җирлеге территориясендә 2018 елның 18 ноябренә җирле референдум билгеләргә.

2. . Җирле референдумга чыгарылучы түбәндәге сорауны расларга:

"Яшәү урыны буенча Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Балык Бистәсе шәһәр җирлеге территориясендә теркәлгән балигъ булган, уку йортларының көндезге бүлекләрендә укучы студентлардан, 1 төркем инвалидлардан, Бөек Ватан сугышында катнашучылардан һәм аларның тол хатыннарыннан һәм тыл хезмәтчәннәреннән гайре, һәрбер кешенең 2018 елда 300 сум күләмендә үзара салым кертүенә һәм җыелган средстволарның түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә:

1.Җирлек территориясен төзекләндерүне оештыруга: Балык Бистәсе штп.территориясендә электр белән тәэмин итү линияләрен капиталь ремонтлауга, реконструкцияләүгә һәм төзүгә;

2.Каты коммуналь калдыкларны җыю (шул исәптән аерым җыю) һәм ташу буенча эшчәнлекне оештыруда катнашуга;

Балык Бистәсе штп.территориясендә каты коммуналь калдыкларны җыю урыннарын җайлаштыруга;

3. Гомуми файдаланудагы су объектларына һәм аларның яр буе полосаларына гражданнарның ирекле үтүен тәэмин итүне кертеп, Җирлек халкының массачыл төстә ял итүе өчен шартлар тудыруга һәм халыкның күпләп ял итү урыннарын җайлы итүне оештыруга: Балык Бистәсе штп. территориясендә пляжны төзекләндерүгә, уңайлы, җитешле итүгә

юнәлтүгә Сез ризамы?

ӘЙЕ ЮК".

3. Әлеге карарның рәсми рәвештә игълан ителгән көннән үз көченә керүен билгеләргә.

4.Карарны Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Балык Бистәсе шәһәр җирлегенең түбәндәге адрес буенча урнашкан махсус мәгълүмат стендында: Татарстан Республикасы, Балык Бистәсе районы, Балык Бистәсе штп., Ленин урамы,48А йорты һәм Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районының http://ribnaya-sloboda.tatarstan.ru. веб-адресы буенча "Интернет" мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге рәсми сайтында һәм http://pravo.tatarstan.ru. веб-адресы буенча "Интернет" мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге "Татарстан Республикасының хокукый мәгълүмат рәсми порталы"ында урнаштырырга.

5. Карарның үтәлешенә контрольлек итүне үземнең җаваплылыкта калдырам.

Татарстан Республикасы
Балык Бистәсе муниципаль районы
Балык Бистәсе шәһәр җирлеге Башлыгы И.Р. Таҗетдинов